**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 109-61 «03 » июнь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 22 октябрендәге 44 номерлы Туйкә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (28.02.2013 № 52, 30.06.2015 №128, 23.08.2018 №108-51, 25.02.2022 №48-27_карарлар редакциясендә)

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 06 апрелендәге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Туйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә 2012 елның 22 октябрендәге 44 номерлы Туйкә авыл җирлеге Советы карары белән расланган Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү тәртибе турында Нигезләмәгә (28.02.2013 № 52, 30.06.2015 №128, 23.08.2018 №108-51, 25.02.2022 №48-27 карарлар редакциясендә) 8.8 пунктындагы 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«9) муниципаль милекне минималь рөхсәт ителгән бәядән сату;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р.закирова